**ГЛАВА БЕРЕЗКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422712, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Березка, ул.Новостройка, 15А

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАЕНЛЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422712, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Каенлык авылы, Новостройка ур, 15А

Тел./факс: +7(84365) 79-2-08, e-mail: Berez.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**21 октябрь 2024 ел** **№ 11**

# Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Бәерле, Олыяз, Зур Починок, Шуман торак пунктларында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Уставының 22 статьясы һәм 2019 елның 22 октябрендәге 22 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә:

1.1. 2024 елның 03 ноябрендә 9.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Бәерле торак пунктында түбәндәге адрес буенча: Бәерле ав., Яшин ур., 34 йорт (ФАП янында);

1.2. 2024 елның 03 ноябрендә 10.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Олыяз торак пунктында түбәндәге адрес буенча: Олыяз ав., Яңа төзелеш ур., (10 йорт янында).

1.3. 2024 елның 03 ноябрендә 11.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Зур Починок торак пунктында түбәндәге адрес буенча: Зур Починок ав., Бакча ур., (5 йорт янында).

1.4. 2024 елның 03 ноябрендә 12.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Шуман торак пунктында түбәндәге адрес буенча: Шуман ав., Үзәк ур., 27 йорт(мәдәният йорты).

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

2.1. Бәерле торак пунктында: «Сез Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Бәерле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, МХО катнашучылардан һәм аларның гаилә

әгъзаларыннан тыш, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләр башкару белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту җайланмасы (урамнарны яктыртуны ремонтлау);

-халык яшәгән җир чикләрендә җирле әһәмиятле җәмәгать юлларын төзү, ремонтлау, хезмәт күрсәтү (авыл эчендәге юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу)

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2.3. Олыяз торак пунктында: «Сез Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Олыяз авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, МХО катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләр башкару белән килешәсезме:

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кышкы тоту: ягулык-майлау материаллары сатып алу, кар чистарту, тракторчының хезмәт хакы)

-табигый җир асты суларының урыннарын яхшырту (чишмәне ремонтлу);

-җирлек территориясен төзекләндерү(балалар мәйданчыгын төзекләндерү)

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2.5. Зур Починок торак пунктында: «2025 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Зур Починок торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

-традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (зиратка хуҗалык корылмаларын төзү турында);

юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2.6. Шуман торак пунктында: «Сез Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Шуман авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, МХО катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләр башкару белән килешәсезме:

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кышкы тоту: ягулык-майлау материаллары сатып алу, кар чистарту, тракторчының хезмәт хакы);

-торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү(янгын сүндерү гидранты төзелеше)

юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көненнән алып 10 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Каенлык авыл җирлегенен
башлыгы А.А.Аминов